**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 26 июнендәге 2699 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 26 июнендәге 2544 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына сатулашулар уздыру тәртибе турында», 2015 елның 16 декабрендәге 4368 номерлы «Казан шәһәре территориясендә шәһәр очрагы килеп чыкканда реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр шартларының үтәлешен тәэмин итү комиссиясе турында», 2021 елның 6 декабрендәге 3210 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру мәсьәләләре буенча комиссия турында» карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетындагы кадрлар һәм структур үзгәрешләргә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 26 июнендәге 2544 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына сатулашулар уздыру тәртибе турында» карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 16 июнендәге 2451 номерлы, 2017 елның 1 мартындагы 539 номерлы, 2017 елның 16 августындагы 3163 номерлы, 2018 елның 12 гыйнварындагы 77 номерлы, 2018 елның 15 октябрендәге 5268 номерлы, 2019 елның 28 маендагы 1944 номерлы, 2021 елның 26 февралендәге 483 номерлы, 2021 елның 6 декабрендәге 3211 номерлы, 2023 елның 17 июлендәге 2008 номерлы, 2023 елның 22 сентябрендәге 2816 номерлы, 2024 елның 12 апрелендәге 1529 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) 2 номерлы кушымтага, Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион үткәрү комиссиясе составыннан Е.В.Максименкованы чыгарып, үзгәреш кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 16 декабрендәге 4368 номерлы «Казан шәһәре территориясендә шәһәр очрагы килеп чыкканда реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр шартларының үтәлешен тәэмин итү комиссиясе турында» карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 апрелендәге 1424 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 2973 номерлы, 2022 елның 25 августындагы 2825 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1 номерлы кушымтаның 1.3 пунктында «Казан шәһәр Думасының 2009 елның 26 ноябрендәге 9-44 номерлы «Казан шәһәрендә реклама конструкцияләрен урнаштыру турында» карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 2 номерлы кушымтада:

2.2.1. Казан шәһәре территориясендә шәһәр очрагы килеп чыкканда реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамәләре шартларының үтәлешен тәэмин итү комиссиясе составыннан О.В.Терентьеваны, И.В.Куляжевны, И.И.Ихсановны чыгарырга;

2.2.2. Казан шәһәре территориясендә шәһәр очрагы килеп чыкканда реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамәләре шартларының үтәлешен тәэмин итү комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә: комиссиянең җаваплы секретаре сыйфатында – Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенең проектлар һәм контроль бүлеге хезмәткәрен, комиссия әгъзалары сыйфатында – И.И.Сәлахетдиновны, Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты рәисен, Т.В.Меженцеваны, Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе җитәкчесе урынбасары – проектлар һәм контроль бүлеге җитәкчесен.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 6 декабрендәге 3210 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру мәсьәләләре буенча комиссия турында» карарына кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. 7 пунктның өченче абзацында «проектлар бүлегеннән» сүзләрен «проектлар һәм контроль бүлегеннән» сүзләренә алмаштырырга;

3.2. 17 пунктта «проектлар бүлеге» сүзләрен «проектлар һәм контроль бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны

Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**